**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТЕЛӘЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(II чакырылыш)**

# КАРАР

**утыз җиденче утырыш**

**2014 елның 16 июле** **№155/1** **Теләче ав.**

**«Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 2014 елның 29 июнендәге 155 номерлы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Теләче авыл җирлеге Советы карарын гамәлгә ашыру хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге Советы карар итте

1. 2014 елда үзара салым акчалары исәбеннән башкарылырга тиешле эшләр исемлеген түбәндәгечә расларга:

- Теләче авылында Теләче елгасын төзекләндерү;
- Теләче, Ачы, Екатериновка, Комаровка торак пунктларында су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау;
- Чишмәләрне ремонтлау: Комаровка авылы янындагы көнчыгыш өлешендә һәм Екатериновка авылы янындагы көнчыгыш өлешендә, күперләрдә: Ачы, Екатериновка, Теләче авылында: Киров, Белов урамы буенча урнашкан.

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Теләче авыл җирлеге башлыгы И.Ф. Зарипов